ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.12.2018 с. Верхний Услон 1436

**«2019 елга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Өстәмә белем бирү үзәге» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесенең туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында»**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга туристик-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы белән туры китереп Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ

1. Утвердить на 2019 год:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Өстәмә белем бирү үзәге» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесендә (алга таба- өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе) балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү

программаларын тормышка ашыруга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Өстәмә белем бирү үзәге» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесендә балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициенты 0,5 күләмендә;

2. Югары Ослан муниципаль районының финанс-бюджет палатасын тәэмин итәргә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнары нигезендә Югары Ослан муниципаль районының Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслау;

- әлеге карарның 1 пунктында расланган Югары Ослан муниципаль районының Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә эш хакы индексы белән бер үк вакытта Югары Ослан муниципаль районының Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнарын яңадан карау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе Л.С. Хакимзянов**

Әзерләде һәм бастырды
5 нөсхәдә
А.З. Халикова

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының
11.12.2018 ел, № 1436 карары белән
РАСЛАНДЫ

**2019 елга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Өстәмә белем бирү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесендә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, сум бер укучыга бер елга | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку еыл | өченче һәм аннан соң уку елы |
| Эстетик-сәнгать | авыл җире | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | авыл җире | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | авыл җире | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экологик-биологик | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социально-педагогическое | авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисадый | авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый фәнни | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |

**Башкарма комитет эшләре белән**
**идарә итүче** **А.К. Мингазова**